| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Яңа Әлмәле авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 январь 2026 ел № 5/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советының 08.11.2019 елның 59/3 номерлы «физик затлар мөлкәтенә салым турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2 пунктка Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советының 08.11.2019 елның 59/3 номерлы «физик затлар мөлкәтенә салым турында " карарын кертергә (редакциядә 19.05.2020 № 65/3, 15.11.2022 №23/4, 13.10.2023 №33/2, 25.09.2024 №41/1, 13.12.2024 №44/3, 14.11.2025 №2/2) түбәндәге үзгәрешләр:

1) 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) РФ Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата РФ Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент;»;

2) түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктча өстәргә:

«4.1) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;».

2. Әлеге карарны Яңа Әлмәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Яңа Әлмәле авыл җирлеге сайтына урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков